

*77 ел элек кvпмиллэтле совет халкы Бөек Ватан сугышында кешелекнен мэрхэмэтсез дошманы – фашизмны тар-мар итте. 1945 елнын  9 май кичендэ тарихтагы ин вэхшэтле, ин канкойгыч, кешелексез сугышнын тэмамлануын, бик озак көтелгэн тынычлык урнашуын белдереп, Ватаныбызнын кvгендэ жинv салюты янгырады.*

Боек Жинv ул – данлы Ватаныбыз тарихынын ин кvренекле вакыйгасы, халыкнын корычтай нык рухы, каһарманлыгы кvрсәткече, гаделлек һәм хаклыкнын явызлык кочләреннән һәм золымнан һәрчак остен чыгуына ачык бер мисал.

Илебезнен vткәне, бvгенгесе һәм киләчәге белән тыгыз бәйләнештәге Жинv Коне сугыштан сонгы буыннар хәтеренә тирән уелды, кvпсанлы һәйкәлләрдә, шәһәрләр, авыллар һәм урамнар атамаларында, музейлар һәм панорамалар экспозицияләрендә мәнгеләштерелде.

Икенче Ботендонья сугышы – кешелек тарихында ин зур фажига,  ул бик кvп дәvләтләргә һәм халыкларга исәпсез-хисапсыз бәлаләр китерде. Әмма ин зур югалтулар, кешеләрнен кvпләп вафат булуы, шәһәрләрнен, авылларнын жимерелvе, юкка чыгуы безнен ил язмышына тоште.

Бvген без, Жинv Конен бәйрәм иткәндә, Россиянен, шул исәптән Мордовиянен һәрбер кешесе Туган жиребезне һәм ботен доньяны нацистлардан каһарманнарча саклап, сугышнын коточкыч тегермәнендә һәлак булган, дәһшәтле бомбага тотулардан, ядрәләрдән гомере озелгән, концлагерьларда юк ителгән, камалыштагы Ленинградта ачлыктан vлгән һәркемнен рухы алдында баш иябез. Сугыш чоры балаларына һәм

яраланып кайткан солдатларга олы хормәтебезне белдерәбез. Тугызынчы май конне алар хормәтенә «Үлемсез полк» һәм митинглар Мордовиянен татар авылларында да vткәрдек, исән калган Боек Ватан сугышы батырларын, сугыш чоры балаларын барлап котладык. Шулай, зурлап «Үлемсез полк» Ләмберә районы vзәгендә, Аксёново, Пензятка, Татар Тавласы, Черемиш, Татар Свербеевкасы, Иняты, Кривозерье (рәсемдә) авылларында vтте; Зубово-Поляны районындагы оч кечкенә генә авыл халкы (Кочетовка-Чатока, Татар Лунданы, Горенка) 9 май - Жинv Конен лаеклы каршы алдылар.



Темников районы Тархан авылында Митингны Тархан урта мәктәбе директоры урынбасары Румия Анвар кызы Шехмаметьева ачып жибәрде, аннары сvзне авыл жирлеге башлыгы урынбасары Гульнара Хафиз кызы Дулатова, ветераннар советы рәисе Герасимова Тамара Григорьевна бирделәр. Барыгызга да сәламәтлек, бәхет, тыныч кvк йозе теләделәр. Мәктәп укучылары концерт программасы әзерләделәр. Барысын да бәйрәм белән котладылар, шигырьләр һәм жырларнын яхшы башкарылуы белән соендергәннәр. Һәйкәлгә веноклар һәм чәчәкләр салганнар. Ә аннары кvккә шарлар очырганнар. Ә район кvләмендә оештырылган «Мы помним!» дигән VII патриотик автопробегта катнашканнар.



Кадошкино районы урта мәктәбенен тәжрибәле тарих укытучысы Равиль Харис улы Казанбаев 9 май бәйрәменә, укучылары белән бергә, алдан әзерләнеп килгән. Шулай, 5 майда оештырылган «9 мая: Победа народа» Ботенроссия ачык олайн-дәрес vткәрә. Бу

районнын Большие Поляны, Латышовка татар авылларында да тантаналы митинг та vткәргәннәр, туган авылы батырларын искә алып, «Үлемсез полк»та катнашучылар гаилә батырларынын фотоларын алып килгәннәр, мәктәп укучылары иншалар язганнар, эзләнv эшләре башкарганнар... – жуелмас хәтерләренә салганнар.



Рузаевка районы Татар Пешләсе авылы халкы «Үлемсез полк»та, Татар Пешлә авылы батырлары һәйкәленә венок һәм чәчәкләр салдылар, митингта катнашканнар. Татар Пишәле авыл жирлеге башлыгы авыл халкына һәм кунакларга котлау сvзе белән морәжәгать иткән, шулай ук Жәмигъ мәчете Имам-хатыйбы догалар укыган, Татар-Пишә клубы vзешчәннәре "Георгий тасмасы" акциясендә катнашканнар, кич «Эхо войны и память сердца» дигән концерт караганнар.

Мордовия татар авылларында сугыш һәм хезмәт ветераннарына чын кvнелдән сәламәтлек һәм иминлек, ә халкыбызнын сугышчан һәм хезмәт даны варисларына илнен оборона куәтен, икътисадый һәм мәдәни vсешен ныгытуда зур унышлар, тынычлык, бәхет һәм кvнел кvтәренкелеге телибез, дигән теләкләр һәр татар авылы кешесенә теләнде.

**Наилә НАСЫРОВА**